ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлегенең Сарман авылында
2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2021 елның 3 декабре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман авылы территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан (студентлар, Кораллы Көчләр сафларында хезмәт итүче затлар), I һәм II төркем инвалидлардан һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнарданнар, хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Сабантуй, Җиңү көне, Өлкәннәр көне бәйрәмнәренә бүләкләр алу, юбилярларны котлау, Сарман авылы;

2) Сарман авылында урам күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

3) Сарман авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү(яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

4) Сарман авылында КФЙ ишегалларын һәм урамнарны төзекләндерү (иске хуҗалык корылмаларын сүтү, коймалар урнаштыру, балалар өчен уен мәйданчыклары һәм МАФлар сатып алу).;

5) Сарман авылында паркларны яшелләндерү һәм карап тоту (печән чабу, инвентарь һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу);

6) тракторга хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, өстәмә җиһазлар, запчастьләр сатып алу, хезмәт өчен түләү);

7) Сарман авылында зиратны карап тоту (зиратны карау, инструментлар алу, хезмәт өчен түләү).

3. Әлеге карарны Сарман авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми

сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе ___________ Н. И.Сахуриев